ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

№ 128 20 02 2023 ел

Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 26 сентябрендәге 731 номерлы карары (2021 елның 15 апрелендәге 259 номерлы үзгәрешләре белән)белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 февралендәге 100 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 26 сентябрендәге 731 номерлы карары (2021 елның 15 апрелендәге 259 номерлы үзгәрешләре белән) белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 1.3 пунктының беренче һәм икенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Компенсация алу хокукын билгеләгәндә, гаиләнең җан башына уртача кереме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында» 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы карары белән билгеләнгән кагыйдәләр буенча исәпләнә (2023 елның 4 февралендәге 100 номерлы үзгәрешләр белән).

Балага түләү билгеләнгәндә гаиләнең уртача җан башына керемнәре гаилә әгъзаларының соңгы 12 календарь айдагы керемнәреннән чыгып исәпләнә, бер айга кадәр балага айлык пособие билгеләү турында гариза биргәнче.».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (//http:pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Спас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин